ТЕЛЕФОН КИРӘК

Элек шәһәр баласы җәен авылга кайтырга атлыгып тора иде, ә хәзер?

> 3

ТӘГӘРМӘЧЛЕ ЙОРТ

Машинада сәяхәт итү – хәзер күпләр өчен гадәти хәл

> 3

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

«Шәһәр кешесенә бик сизелми торгандыр инде бу, ә авылда сизелә»

> 4

ӘБИЛӘР БӘЙРӘМЕ

өлкән буынга хөрмәтне күрсәтә, киләчәктә дә асылын югалтмаска иде

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 86 (29053) | Сишәмбе | 20 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ЙӨРӘК ЭШЕ

КАЗАНДА «АК ЧӘЧӘКЛӘР» БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕН БҮЛӘКЛӘДЕЛӘР

Бу хезмәтнең алы да, ялы да юк. Ләкин гомер юлдашы итеп шушы һөнәрне сайлаган кеше инде тормышын ансыз күз алдына да китерә алмый. «Казан Экспо» үзәгендә медицина тармагында әнә шулай фидакарьләрчә хезмәт куйган иң яхшы табибларны хөрмәтләделәр.

tatarstan.ru

Бәйгедә «Ел табибы» исеменә Айнагөл Баялиева (уңнан икенче) лаек булды.

«Ак чәчәкләр» бәйгесе унбишенче тапкыр уздырыла. Анда алты номинациядә җиңүчеләр билгеләнде. Татарстан сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин сүзләре белән әйтсәк, гади бәйге генә түгел, шушы җаваплы эштә булган белгечләргә бер җыелып күрешү өчен бер сәбәп тә бу.

– Медицина хезмәткәрләре – дөньядагы иң катлаулы һөнәр ияләре. Алар өчен бәйрәм дә, ял да юк. Әле генә һөнәри бәйрәмебезне билгеләп үттек. Күпләр аны операция өстәле янында, «Ашыгыч ярдәм» машинасында, авырулар янында каршы алды, – диде министр.

Бүген республиканың сәламәтлек саклау тармагында 37 меңнән артык урта медицина хезмәткәре эшли. Быел әлеге тармактагы иң яхшы хезмәткәр дип Республика клиник онкология диспансеры шәфкать туташы Миләүшә Шәрәфетдинова табылды.

Үзебезне аз гына начар хис итә башласак, иң беренче эш итеп участок табибы, педиатр ишеген шакыйбыз. «Ак чәчәкләр» бәйгесендә «Иң яхшы беренчел звено табибы» исеменә Яшел Үзән районының Васильево бистәсе табиб-педиатры Николай Романов лаек булды. Райондагы иң зур участокка хезмәт күрсәтә табиб. Ул эшләгән өч ел вакыт эчендә район үзәк хастаханәсенең педиатрия бүлегендә балаларны диспансерлаштыру, вакцинацияләү күрсәткечләре яхшырган.

Табиблар өчен һәр авыру – җаваплылык. «Ак чәчәкләр»дә яңгыраган истәлек-хатирәләр табибларның көндәлек батырлыгына тагын бер кат инандырды. Аларның һәркайсының тетрәнеп, кайчак җиңел сулап искә алырлык гыйбрәтле тарихы бар. Коронавирус дигән зәхмәт пәйда булгач, табибларның иң кирәкле, кадерле кеше икәненә инандык инде. Алар башкарган батырлыклар турында ишеткәч, бу фикернең хаклыгына тагын бер кат инанасың. Татарстан табиблары ясаган кайбер катлаулы операцияләргә хәтта федераль үзәкләрдә дә алынмыйлар. Шундый операцияләрнең берсе узган ел Чаллыда ясалган. Автокаланың Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе табиблары Россиядә беренчеләрдән булып кеше организмындагы иң зур кан тамырларын алыштырган. Табиблар күкрәк һәм корсак аортасын тулысынча протезлый, аның йөрәктән алып аяк артерияләре очына кадәр булган мөһим тармакларын саклап калган.

Шул рәвешле Чаллыда яшәүче дүрт бала атасы Тәһир Кадыйровка икенче гомер бүләк иткән алар. «Бүген исән-сау булуым, үз аякларымда йөгереп йөрүем өчен табибларга гомер буе рәхмәт укыячакмын. Чын мәгънәсендә икенче гомер бүләк иттеләр. Исән-сау балаларымны аякка бастырырга язсын», – диде ул «Уникаль очрак» номинациясендә җиңү яулаган табиблар турында.

Шушы ук номинациядә катнашкан башка табибларның да каһарманлыгы алдында баш иярлек. РКБ, 16 номерлы шәһәр хастаханәсе, Республика клиник онкология хастаханәсе табиблары күкрәгендә дүртенче дәрәҗәдәге яман шеше булган хатын-кызга әни булырга ярдәм иткән, ананың да, баланың да гомерен саклап калган. ДРКБ табиблары исә баш миенә кан сауган тугыз яшьлек Әскәрне коткарган. Казанның 1 номерлы балалар хастаханәсе табиблары вакытыннан алда 680 граммлы булып туган кызчыкның гомерен саклап калган. Бүген Әминәгә 12 яшь. Кыз профессиональ рәвештә фигуралы шуу белән шөгыльләнә. Узган ел Махсус Олимпиадада алтын медаль яулаган. Үзен коткарган фидакарь табибларны котлап, бәйрәм тантанасында аларга бию бүләк итте ул.

– 45 яшьтә әни булдым, менә инде ун елдан артык шушы бәхетне татуымны дәвам итәм. Хәзер бу табиблар безгә туганнарыбыз кебек якын. Аларга көн саен рәхмәт укыйм, – ди кызның әнисе Фәридә Закирҗанова.

Бәйгенең бүләкләү тантанасында катнашкан Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов табибларга соклануын яшермәде.

– Битараф булмаган кеше генә шушы катлаулы һөнәрне сайлый ала. Безгә бүгенге видеоязмаларны караганда да кыен булды, ә сез көн дә шундый очраклар белән очрашасыз. Хезмәтегез бик катлаулы. Без сезгә иң кадерле әйберне – сәламәтлегебезне ышанып тапшырабыз, – диде ул. – Республикада медицина ярдәме күрсәтү эшен яңартуга, алдынгы технологияләр үзләштерүгә, туучылар санын арттыру, гомер озынлыгын озайтуга зур игътибар бирелә. Без бу эшне алга таба да дәвам итәчәкбез. Медицина хезмәтенә һәрчак сорау зур. Бүген медицина хезмәткәрләре махсус хәрби операция зонасында да алдынгы сафларда тора. Табиб һөнәре – бик күп көч таләп итә торган хезмәт. Без сезнең эшкә һәрчак теләктәшлек күрсәтәчәкбез.

Ахыры 3 нче биттә >

Күзәтеп торалар

Казандагы социаль учреждениеләрдә иминлек системасын урнаштыру һәм яңарту өчен соңгы өч елда 600 млн сум акча сарыф ителгән. Барлык мәктәп һәм балалар бакчаларына контроль һәм керү белән идарә итү системасы урнаштырылган. Бу хакта башкала мэриясендә узган «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә шәһәрнең мәгълүмати технологияләр һәм элемтә идарәсе башлыгы Дмитрий Кремлев әйтте.

176 мәктәп һәм 223 балалар бакчасы сак сигнализациясе системасы белән җиһазландырылган. Тавыш белән хәбәр итү системасы Казанның 172 мәктәбендә һәм 274 балалар бакчасында урнаштырылган.

Шәһәр мәктәпләренең барысы да видеокүзәтү камералары белән җиһазландырылган – аларда 5349 видеокамера урнаштырылган. 357 балалар бакчасында 5867 тышкы күзәтү камерасы бар.

Башта эшлибез

Россиянең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы 2024 елда ял һәм бәйрәм көннәрен күчерү турындагы карар проектын әзерләгән. Документ кабул ителгән очракта, Яңа ел бәйрәмнәрендә – 10, ә май аенда ике мәртәбә 4әр көнлек яллар көтелә. Бу хакта министрлыкның «Телеграм»дагы каналында хәбәр ителә.

Яңа ел яллары 1 гыйнвардан 8енә кадәр дәвам итә. 30 һәм 31 декабрь шимбә һәм якшәмбегә туры килгәнлектән, ял көннәре 10 көнгә сузыла. Май бәйрәмнәрендә 28 апрельдән 1 майга һәм 9 майдан 12сенә кадәр ял итәчәкбез. Ватанны саклаучылар көне уңаеннан 23 февральдән 25енә кадәр ял вәгъдә ителәр. Халыкара хатын-кызлар көне 8–10 март көннәрендә ял итү мөмкинлеге бирәчәк.

Табынны бергә корабыз

Татарстанда яшәүчеләрдән аш-су рецептларын туплап, җыентык чыгарырга ниятлиләр. Бу хакта «Татар-информ» хәбәрчесенә Татарстан вице-премьеры Ләйлә Фазлыева әйткән. Киләсе ел Сабан туенда төп игътибарны татар ашларына бирү теләге дә бар.

«Мондый китапны әзерләргә бер елдан артык вакыт кирәк була. Башта рецептларны җыярга, аннары төзәтергә кирәк. Без Казан инновацион университеты, Татарстан Фәннәр академиясе, Рестораторлар һәм отельерлар ассоциациясе президенты Зөфәр Гаязов белән татар халык аш-сулары китабын чыгардык. Без аны тулыландырырга телибез», – дигән Ләйлә Фазлыева.

Казанда аш-су рецептларын башкала Сабан туена бүләк җыйганда туплый башлыйлар. Аннары аларны махсус адреска юллап булачак.

Индар Мехәммәтҗанов

Фажига

Утлы якшәмбе

Сәет авылында көпә-көндез чыккан янгында 7 кешенең, шул исәптән 4 баланың гомере үзелде. Аларның 28 яшьлек әниләре генә исән калды. Тукай районында булган фажигадән соң Татарстан Рәисе янгынга каршы уздырылган чараларны көчәйтергә кушты. Йорт саен йөреп, иминлек кагыйдәләрен искә төшерәчәкләр.

mchs.gov.ru

Рөстәм Миңнеханов бу эшне эзлекле рәвештә алып барырга һәм тиешле хезмәтләрне җәлеп итәргә, күпбалалы гаиләләргә аерым игътибар бирергә, һәрберсен күзәтеп торырга күрсәтмә бирде.

Сәет авылындагы фажига турында хәбәр янгын сүндерүчеләргә якшәмбе көнне 13 сәгать 17 минутта килеп ирешә. Бүрәнәдән салынган йорттагы утны сүндерергә 43 кеше юлга чыга, 17 техника җәлеп ителә. Ялкын бөтен йортны ялмап ала. Коткаручылар башта – 3, аннары тагын 4 кешенең мәетен таба. Шаһитлар әйтүенчә, ут шулкадәр тиз тарала, күрше-тирәдә яшәүчеләр берни аңламыйча да кала. Сәет авылы халкы күз яшьләрен түгә.

Ниләр булганын ачыклар өчен, Сәет авылында яшәүчеләр белән элемтәгә кердек. Алар барысы да кара кайгыда. Сизелеп тора: хәлләре сөйләшерлек түгел. Гардановларның терәлеп торган күршеләре Айсылу да: «Шулкадәр тетрәндерде бу фажига. Бер мәлгә үз исемемне дә оныттым. Бик кыен хәл», – дип телефонын куйды.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстандагы баш идарәсе мәгълүматларына караганда, ут чыккан гаилә бик үк имин булмаган. Дөрес, аларны белгән кешеләр балаларга игътибар җиткәнен әйтә.

– Алар бер йортта сигез кеше яши иде. Әниләре Гүзәлия улы, кызы, кияве, оныклары белән бергә торды. Уллары Ильмир өйләнмәгән иде әле. Ә менә кызлары Ильмира мәктәпне тәмамлауга кияүгә чыгып куйды. Айнур белән матур гына яшиләр иде алар. Дүрт балалары булды. Зурлары – 10 һәм 9 яшьлек ике малай коррекцион мәктәптә укый иде. Өченче уллары быел шул мәктәпкә укырга барасы булган. Кечкенә кызларына 5 яшь кенә тирәсе иде, – ди исемен әйтергә теләмәгән авылдашлары. – Сабыйларның әниләре Ильмира, тавыкларны ашатырга дип, урамга чыккан булган. Шул арада ничек йортларына ут капкандыр? Аптырадык инде ишеткәч. Ильмира бу ачы хәсрәткә ничекләр түзәр инде... Бер мизгелдә әниең, балаларың, абыең, иреңне югалту бит!

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Ольга ВАСИЛЬЕВА, Россия мәгариф академиясе президенты:

Ата-аналарның 5 проценты – бер яшьлек балага, 99 проценты алты яшьлек балага гаджет тоттыра. Ягъни бала инде мәктәпкә хәтле үк цифрлы дөньяга чума. Ә белгечләр әйтүенчә, үсешенә тискәре йогынты ясамасын өчен, баланы 2 яшькә хәтле цифрлы җайланмаларга якын да җибәрергә киңәш ителми.

(«Парламентская газета»га әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – ХЕЗМӘТ БАЗАРЫ

SuperJob хезмәте белгечләре Россиянең иң зур шәһәрләрендәге хезмәт базарына күзәтү ясаган һәм иң зур хезмәт хакы тәкъдим ителә торган вакансияләрне сайлап алган. Казанда иң яхшы хезмәт хакы ала торган хезмәт ияләре сервис инженерлары икән.

Һөнәр	Тәкъдим ителә торган хезмәт хакы, сумнарда
Сервис инженеры	150000 – 200000
Дизайнер-консультант	150000
Сату буенча менеджер	112000
Автоматика буенча инженер (РЗА)	100000нән башлап
Техник күзәтү бүлеге инженеры	85000нән башлап

Җылырак киенеп йөрисе

Татарстан Гидрометеоүзәк белгечләре фаразларына караганда, суык көннәр атна ахырына кадәр дәвам итәчәк. Сишәмбе республика аша атмосфера фронты узып, бераз яңгыр явуы көтелә. Чәршәмбе төнлә температура 3–8, ә көндез 14–19 градус җылы булачак. Кайбер районнарда яңгыр явачак.

22 июньдә атмосфера басымы күтәрелә. Көндез температура 15–20 градус җылы булачак. Җомга һәм шимбә исә көндез 19–24 градус җылы булыр дип фаразлыйлар. 24 июньдә яңгыр да яварга мөмкин.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БЛИНКЕН – КЫТАЙДА

Үткән атна зур державаларның уртак тел табарга омтылышлары белән узды. Дөресрәк итеп әйтсәк, зур кризис һәм ихтималлыгы югары булган кораллы конфликтлар алдыннан глобаль сәясәт кырында уйнаучы яклар юрганны үз якларына тартырга, аркадашлык мәсьәләләрен яңабаштан карарга омтыла.

Икътисад лидерлары булып саналган дәүләтләрнең хәлләре бик үк яхшы булмау, көннән-көн начараю вазгыятькә яңача карарга мәҗбүр итә. Инфляция вирусы дәүләтләрнең куәтен кимерә, бурычлар күләме муенга эленгән таш булып төпкә сөйри, үзара конфронтация хәлне авырайта – болар барысы да бик аңлаешлы нәрсәләр. Киләчәктә зур кораллы конфликт була калса, аны уңайрак диспозициядә башлау кирәклеген дә барлык лидерлар да төшенә.

Планетакүләм мәйданда төп уенчы булган АКШта дүртенче ай рәттән инде ваклап сату сәүдәсенең реаль күләме кими. Түбәнәю уртача 2,3 процент дип исәпләүләр. Бу 2008–2009 елгы кризистагы кадәр үк түгел әле. Ул чакта 2008 елның ноябреннән 2009 елның маена кадәр аралыкта ваклап сату уртача 10,6 процентка кимегән. Тагын бер нәрсә бар: алдагы айларда АКШта сатып алу күләме кискен арткан булган, ягъни агымдагы түбәнәю бик югары ноктадан башланган. Димәк, бу әле кискен кризис түгел, әмма юнәлеш түбәнәюгә таба.

Икенче зур икътисад – Кытайда да хәлләр шәп түгел: кредитлау кими, үсеш темплары түбәнәя. Икътисадый үсешнең төп индикаторы булган нефть бәясе, чыгаруны киметү турындагы игъланнарга карамастан, көтелгән югарылыкка ирешми. Үткән ялларда АКШның дәүләт секретаре Энтони Блинкен Пекинга юл тотты. CNN телеканалы бу уңайдан визитның мөһимлеген, ике ил арасындагы мөнәсәбәтләрне берничә айлык киренкелектән соң тиешле агымга кире кайтаруны максат итеп куюын игълан итте.

Конфронтация Кытай өчен дә шәп түгел. Үсеп килүче илләрне доллар бәйлелегеннән коткару максатыннан чиннар төзегән БРИКС үсеш банкы авыр сулыш ала: кредитлауны туктатты, әҗәтләрен каплау өчен долларлар эзли. Банкның рейтингы түбәнәйтелде, шул сәбәпле аңа капитал базары бикләнде, бурычка акча алыйм дисә, 4–5 тапкыр кыйммәткәрәк кенә таба ала. Искә төшерик: банкның 20 процентына Россия хуҗа.

Блинкенның Кытайга килүе шуңа күрә ике як тарафыннан да көтелгән нәрсә. Кытайның тышкы эшләр министры Цинь Ган, Блинкенны каршы алганда, Кытай – АКШ мөнәсәбәтләренең ике ил дипломатиясе тарихында иң түбән дәрәҗәгә төшүен билгеләп үтте һәм: «Кытай АКШ белән тотрыклы, конструктив мөнәсәбәтләр төзергә омтыла», – диде. Сер түгел: Блинкен сөйләшүләр үзәгенә Россия – Украина конфликтын да куя ният белән килде. АКШ Дәүләт секретареның бу визиты соңгы биш елда югары чиндагы дипломатның Пекинга беренче килүе буларак та әһәмиятле. Ике көнлек визит вакытында ул, бәлки, Си Цзиньпин белән дә очрашыр, диләр. Очрашу нәтиҗәләре планетадагы вазгыятькә йогынты ясаячак.

Россиядә

ИСТАНБУЛ КИЛЕШҮЕН САГЫНГАНДА

Сәяси шахмат тактасында диспозицияләрне үзгәртергә теләк Мәскәүдә дә сизелә. Петербург халыкара икътисадый форумның чираттагысы шул максатларга ирешүнең бер баскычы булырга тиеш иде. Форумга төрле күзлектән карап бәя бирергә мөмкин. Андагы кайбер чыгышларга ышансак, Россиянең хәлләре көтелгәннән яхшырак. Гомумән, Россия ягыннан форумга гел оптимистлар гына җыелган иде.

Форумның төп вакыйгасы Владимир Путинның рекордлы озынлыкта чыгышы булды. Кремль лидеры алдагы көннәргә зур максатлар билгеләде. Аның фикеренең төп сөземтәсе шул: товарларга ихтыяҗ тууын көтеп торырга кирәкми, ихтыяҗны булдырырга кирәк. Аңлашыла инде: ихтыяҗ тусын өчен, халык кесәсе калын булырга тиеш. Кесәне калынайтуның төп юлы – хезмәт хакларын үстерү.

Әлегә Россиядә аерым тармакларда ярыйсы гына үсеш күзәтелә. Әмма аны финанс министры Антон Силуанов әфәнде «кызу» (перегрев) дип атады. Икътисад кредитлау хисабына үскәндә шулай була: башта зур алгарыш, аннан соң кискен егылу күзәтелә. Россиядә хәзер шуның беренче этабы күзәтелә. Бу бигрәк тә төзелеш тармагына хас.

Петербург форумы халыкара очрашу һәм килешүләр төзү урыны буларак әһәмияткә ия. Россиянең төп уңышларының берсе – изоляциядән котылу, Көнбатыш державалары планлаштырган блокаданың барып чыкмавы. Бу уңышта Мәскәү дипломатларының өлеше күпмедер, әмма көтмәгәндә дөнья, АКШ мәнфәгатьләренә каршы килеп, ике лагерьга бүленде. Санкцияләр белән чамасыз мавыгу Көнбатышка аю хезмәте күрсәтте: өченче дөнья илләре дәррәү рәвештә икътисадый яктан үсешкә ирешкән илләргә каршы лагерьга тупландылар. Берләшкән Гарәп Әмирлекләре җитәкчесе бу хакта Путинга: «Президент әфәнде… Россиядәге хәзерге вазгыятьне исәпкә алып, безнең тарафка бик күп янаулар килә, әмма без Көнбатыш куйган шартларга бәйсез рәвештә карар кабул иттек һәм (Россия белән хезмәттәшлеккә таба) адым ясадык», – диде.

Петербургка тыныч инициативалар белән Африка дәүләтләре делегациясе килде. Путин алар белән очрашканда, өстәлгә узган елгы Истанбул килешүен чыгарып салды. Кремль лидерының тел төбеннән шул аңлашыла: Долмабахчә музеенда нигез салынган килешү Мәскәүне канәгатьләндерәсе булган. Киев яныннан Россия гаскәрләрен чыгаруны Кремль шул килешү нәтиҗәсе дип саный. Украина килешүгә хыянәт итте дип раслый. Әйе, Буча фаҗигасен сәбәп итеп, Киев Мәскәү белән сөйләшүләрне дәвам иттерүдән баш тартты шул. Югыйсә Путин – Зеленский очрашуы һәм анда Кремль лидеры кулындагы килешү имзалануы көтелгән иде. Якларның икесе дә тиешле сыгылмалык күрсәтеп бетерә алмагандыр, мөгаен, ул чакта. Хәзер инде Истанбул сөйләшүен сагынып искә алырга гына калды.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

БАКУГА ЮЛ БАР

tatarstan.ru

Икътисад һәм Сабан туе. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Азәрбайҗанга сәфәр кылды.

Рөстәм Миңнеханов иң элек Азәрбайҗан Республикасы Президенты Илһам Алиев белән «Auto Leasing Azerbaijan» сервис үзәген ачу тантанасында катнашты. Ул «КАМАЗ» ГАҖ һәм Гәнҗә автомобиль заводы катнашында төзелгән. Биредә теләсә нинди авырлыктагы ремонт эшләрен башкарып булачак. Сервис үзәгендә «КАМАЗ» гына түгел, ә башка төр техникага хезмәт күрсәтергә дә җыеналар. Азәрбайҗан Президенты әлеге үзәкне бик кирәкле дип атый. Ник дигәндә, биредә масштаблы төзелеш эшләре алып барыла, аларга йөзләгән берәмлек техника җәлеп ителгән. Рөстәм Миңнеханов үз чиратында Илһам Алиевка проектка игътибар биргәне өчен рәхмәт белдерде.

Узган ел нәтиҗәләре буенча Татарстан белән Азәрбайҗан арасында товар әйләнеше 125 млн доллардан артып киткән. Быелның беренче өч аенда гына да үзара сәүдә, 16 процентка үсеп, 20,5 млн доллар тәшкил иткән. Татарстан Азәрбайҗанга авыл хуҗалыгы, фармацевтика, кәгазь продукциясен экспортлый. Азәрбайҗаннан безгә, үз чиратында, нефть продуктлары, минераллар, җиләк-җимеш кертелә. «Безнең республикаларны Идел һәм Каспий бәйләп тора. Безгә Идел-Каспий бассейнының транспорт һәм логистика мөмкинлекләрен активрак кулланырга кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Азәрбайҗан Президенты Татарстан җитәкчелегенә проектларны тормышка ашыруга күп көч куюлары өчен рәхмәт сүзләре җиткерде.

– Без инде делегацияләр алмаштык, консультацияләр үткәрдек. Сәнәгать кооперациясе буенча зур мөмкинлекләр ачыла. Мәдәни хезмәттәшлеккә дә өмет зурдан. Безнең арадагы мөнәсәбәтләр – Россия белән Азәрбайҗан арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуга да зур өлеш кертте, – диде Илһам Алиев.

Ныгыту дигәннән, эшлекле сәфәр барышында Рөстәм Миңнеханов Бакудагы Сабан туенда да катнашты. Татарстан Рәисе, милләттәшләребезне сәламләп, милли бәйрәмебезнең мөһим ягына игътибар итте.

– Татарлар кайда гына яшәмәсен, Сабан туе безнең барыбыз өчен дә иң яраткан һәм көтеп алган вакыйгаларның берсе булып кала. Аның үзенчәлеге шунда ки, ул бер мәйданчыкта барлык милләт һәм дин вәкилләрен берләштерә, – диде Рәис.

Соңгы мәгълүматлар буенча, бүген Азәрбайҗанда 27 меңнән артык милләттәшебез яши. Биредә «Яшьлек» Татар яшьләре үзәге, «Туган тел» татар мәдәнияте җәмгыяте, «Татарстан» иҗтимагый берләшмәсе, «Ак калфак» хатын-кызлар җәмгыяте кебек берничә берләшмә эшли. Аларда үзешчән сәнгать коллективлары хезмәт куя.

Рөстәм Миңнеханов Азәрбайҗан җитәкчелегенә, Президент Илһам Алиевка татар җәмәгатьчелегенә игътибары һәм ярдәме өчен рәхмәт белдерде. Азәрбайҗанда ватандашларыбызга үз гореф-гадәтләрен һәм йолаларын тормышка ашыру, үтәү өчен барлык мөмкинлекләр булуын да искәртте ул.

– Азәрбайҗан белән Татарстан арасында багланышлар елдан-ел ныгый. Сезнең тырышлык белән биредә татар тормышы гөрләп тора, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Кадерле дуслар

Без ялгыз түгел. «Бердәм Россия» партиясе генераль советының халыкара хезмәттәшлек һәм чит илдәге ватандашларга ярдәм итү буенча комиссиясе утырышында илнең тышкы сәясәте концепциясе турында сөйләштеләр. Комиссия рәисе, Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавров уздырган чарада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, партиянең республика бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Сергей Лавров әйтүенчә, Россиянең якын чит илләрдә, Азия, Африка һәм Латин Америкасында партнерлары бар. Утырышта ул илнең тышкы сәясәте юнәлешендә ниләр эшләнүе һәм эшләнәчәге турында сөйләде.

Фәрит Мөхәммәтшин исә яңартылган тышкы сәясәт концепциясенең көн кадагында булуын әйтте. «Без дус илләрнең иҗтимагый оешмалары һәм партияләре белән эшне яңача көчәйтергә тиеш. Дөньяда безгә тартылучылар күп. Моны Казанда узган «KazanForum – 2023» халыкара форумында да күрдек. Кытай тарафыннан зур кызыксыну бар. Петербург икътисадый форумы да дус һәм нейтраль илләрнең Россия белән хезмәттәшлеккә омтылуын күрсәтте», – диде ул.

Дәүләт Советы Рәисе төбәкләр арасында төрле милләт кешеләрен берләштерүдәге хезмәттәшлекнең әһәмиятенә дә тукталды. «Бер-береңнең гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен хөрмәт итүгә нигезләнгән мондый берләшү ил өчен катлаулы чорда аеруча ачык чагыла», – диде ул. Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, партиянең үзәк органнары төбәкләрдәге оешмалар белән бергәләп эшләргә тиеш.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СУДЬЯЛАРНЫҢ КВАЛИФИКАЦИЯ КОЛЛЕГИЯСЕНДӘ ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК ВӘКИЛЕ ВАКАНСИЯСЕН БИЛӘҮГӘ КАНДИДАТЛАРНЫ АЛДАН САЙЛАП АЛУНЫҢ БАШЛАНУЫ ХАКЫНДА БЕЛДЕРҮ

Татарстан Республикасы Судьяларның квалификация коллегиясендә бер җәмәгатьчелек вәкиленең вәкаләтләре тәмамлану вакыты җитеп килүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Судьяларның квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле вакансиясен биләүгә кандидатларны алдан сайлап алу игълан ителә.

«Татарстан Республикасы Судьяларның квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Судьяларның квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре итеп 35 яше тулган, югары юридик белемле, намусына тап төшерә торган гамәлләр кылмаган, дәүләт яки муниципаль вазыйфалар, дәүләт яки муниципаль хезмәт вазыйфалары биләмәүче, аларның оештыру-хокукый рәвешенә һәм милек рәвешенә карамастан, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре, адвокат һәм нотариус булып эшләмәүче Россия Федерациясе гражданнары билгеләп куела ала.

Кандидатларны алдан сайлап алу Татарстан Республикасы Президентының 2002 елның 17 октябрендәге ПУ-880 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 20 ноябрендәге ПУ-768 номерлы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 14 апрелендәге 233 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Судьяларның квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиллегенә кандидатларны алдан сайлап алу тәртибе турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Җәмәгать берләшмәләренә, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, югары белем бирү мәгариф оешмаларына һәм башка оешмаларга кандидатлар буенча тәкъдимнәрен әлеге белдерү басылган көннән соң 15 календарь көн дәвамында җибәрергә тәкъдим ителә.

Элемтәгә керү өчен телефон: (843) 567-88-33

Утлы якшәмбе

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Сәет Сәмәкәй авыл җирлегенә керә. Урта мәктәп директоры Ләйсән Сәгыйтова әйтүенчә, балалар укырга йөргән, өйләрендә тәртип булган. Бу гаилә турында бернинди начар сүз дә әйтә алмыйм, ди.

Фаҗига булган урынга Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча баш идарәсе җитәкчесе Рафис Хәбибуллин белән Тукай районы башлыгы Фаил Камаев та килгән. Район башлыгы җирле хакимиятнең янгында һәлак булганнарны җирләүне үз өстенә аласын әйткән.

– Бөтенебез өчен зур кайгы бу. Әлегә янгын чыгуның сәбәпләрен тикшерәләр. Бу гаиләгә без бер булышкан идек инде. Ул чакта йортны сатуга бәйле күңелсезлекләр булды. Без йортны үзләренә кайтарып биргән идек. Ут чыбыкларын яңарттык, газ плитәсе алып бирдек, янгын куркынычы турында хәбәр бирүче җайланма да куйдырткан идек. Менә болай тәмамлануы бик кызганыч, – дигән ул.

Сәет авылына район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Илфак Бариев та барган.

– Бу гаилә турында 2020 елда районга хәбәр килде. Өйләрен җыештырмыйлар, тәртип юк, дигәннәр иде. Дүрт бала бар бит! Шундук район социаль яклау бүлеге белән мәктәп җитәкчелеге гаиләгә барды. Өйләрен тәртиптә тотарга, керләрен юарга, җыештырырга өйрәттеләр. Иганәчеләр ярдәме белән кер юу машинасы бирелде, өйләренә ремонт ясалды. Өйдәге ике кечкенә баланы бакчага урнаштырдык. Бер ел буе алар күзәтү астында торды. Тәртип урнашкач, исәптән төшердек, – ди җитәкче. – Әле 7 июньдә мәктәп директоры өйләренә килеп киткән була. Әйтәм бит, исәптә тормасалар да, без аларны контрольдә тоттык. Фермада эшлиләр иде. Ильмираның ире Айнур 45–50 мең сум тирәсе хезмәт хакы алган икән. Әле менә документларын караган идем. Әниләре Гүзәлия 20 мең сум алып барган. Аңа 51 яшь кенә иде әле. Ильмир төнге 12дә кырдан эштән кайткан була. Ильмира да, рәсми төстә булмаса да, эшләп йөргән. Әгәр документ белән урнашса, бала пособиесен югалтырмын дип курыккан. Без гаиләнең хәленә кереп, моңа күз дә йомган идек инде.

Илфак Бариев әлеге гаилә турында күп мәгълүмат белә булып чыкты. Янгын турында хәбәр бирүче җайланма төзек, батареяләры да алыштырылуын, кайчан килеп кермә, суыткыч тулы ризыклары торуын да әйтә җитәкче.

– Ильмираның әтисе белән әнисе аерылышкан иделәр. Әтиләре шушы авылда яши. Ильмира шунда күченә, – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ИХ, АЛМАГАЧЛАРЫ!

Моңа кадәр төзелеш фирмасын җитәкләгән Альфред Хәйруллин 2016 елда тормышын тулысынча үзгәртергә карар кыла. Туган якларына, Чүпрәле районының Дуван авылына кайтып, күптәнге хыялын тормышка ашырырга керешә. Күпләр өчен яңа тармак – бакчачылыкка алыныш, кап-кара туфракта бакча җиләге, карлыган, кура җиләге һәм алма үстерә башлый.

Бүген авыл эшмәкәре – Татарстандагы иң зур алма бакчасы хуҗасы. Ул 200 гектарда берничә төр алмагач үстерә. Искиткеч хезмәт, тырышлык, үҗәтлек һәм, әлбәттә инде, финанс мөмкинлеге таләп итә торган бакчачылык тармагын җәелдерергә үзеннән зур өлеш кертә Альфред Хәйруллин.

– Районның ул вакыттагы башлыгы Александр Шадриковка шалтыратып, туган якларга кайтып, җиләк-җимеш үстереп карау теләгемне җиткердем. «Әйдә, кайт, булдыра алганча үзем дә булышырмын», – диде. Шулай итеп, эшебезне 6 гектар җирдән башладык. Беренче елны виктория, кура җиләге утырттык. Икенче елны ук зур уңыш алдык. Җирне яратырга кирәк аны. Ярату ике яклы булганда гына уңышка ирешергә мөмкин, – ди ул.

Бераздан Альфред Хәйруллин крестьян-фермер хуҗалыгы оештырып җибәрә, «Дуван бакчалары» дип аталган авыл хуҗалыгы кооперативы булдыра. Бүген фермер 7 гектар җирдә – виктория, 7 гектарда – кура җиләге, 35 гектарда карлыган үстерә.

– Җиләкнең иң зур уңышын өч ел элек җыеп алдык: гектарыннан 13 тонна җиләк алган идек. Җиләк-җимешкә ихтыяҗ бик зур. Үзебезнең тирә турында әйтмим дә инде, Мәскәү, Самарадан кадәр чират торып алып китеп бетерәләр. Ләкин хәзер без күбрәк Ульяновскига сатабыз. Алар көненә 500–600 килограммга кадәр алып китә. Карлыган, кура җиләгеннән кайнатма да ясыйбыз, ләкин алай ук зур күләмдә түгел, чөнки өлгерү белән үк алып бетереп баралар, – диде ул.

Шуннан соң тагын бер зур юнәлеш – бакчачылыкка алына ул. Иске алмагач бакчаларын алып, аларны яңартырга керешә. 7 гектардан башланган эш бүген 200гә кадәр җиткән. Аның алмагач бакчасын күреп, һушыбыз китте. Быел, узган көз утырткан үсентеләр белән бергә, 3–4 еллык яшь агачлар да бар һәм алар бик күп. «Эх, язын, алмагачлар чәчәк аткач, монда күз явын алырлык матурлык була торгандыр!» – дигәч, эшмәкәр: «Көзен килегез сез, берничә елдан алма исеннән башлар әйләнә торган булачак монда!» – диде. Алмагачларның бер төре уңышны июль башыннан бирә башлый икән. Ләкин күпчелеге – соң өлгерә торган сортлар. Эшмәкәр алма бакчасына зур өметләр баглый.

– Алманың беренче уңышын узган ел җыеп алдык. Без алмагачларга зур игътибар бирәбез, аларны сабый бала тәрбияләгән кебек карап үстерәбез. Киләчәктә республика балаларын һәм укучыларын бары тик үзебездә үскән алмалар белән генә сыйларга ниятлибез. Бездә Россиянең көньягында гына үсә торган «Гала», «Гренни» сортларына охшаш «Беркутов» сортлы алмалар бар. Алар – зур, кызыл, сусыл. Үсентеләрен Мичуринскидан алып кайтабыз. Шулай ук без үзебездә дә питомник булдырырга ниятлибез. Кайбер үсентеләрне инде сатабыз. Бу эш җиләк сатуга караганда да отышлырак.

Хуҗалык янындагы участокта төзелеш эшләре баруына игътибар итеп, аның белән дә кызыксындык.

– Без җиләк-җимеш үстерү, саклау һәм эшкәртү буенча Россиядәге иң алдынгы хуҗалыкларны йөреп чыктык. Краснодар һәм Тамбов өлкәләренә барып, тәҗрибә уртаклаштык. Шуннан соң кооперативлар арасында грант алыр өчен бәйгедә катнашырга булдык. Аның өчен 1 мең тоннага исәпләнгән җиләк-җимеш саклау проектын эшләдек. Ул зур бер суыткыч кебек булачак, һәркайсы 150 тонна алма саклана торган камералардан торачак. Җиләк-җимешкә дә, алмага да суык кирәк. Әйтик, өзеп алган җиләкне ярты сәгать эчендә салкынга куйган очракта, саклану вакыты 2–3 көнгә арта. Безнең тагын шундый ике суыткыч төзү планыбыз бар.

Виктория, кура җиләге, карлыган һәм алма. Шушы җиләк-җимешнең кайсы үстерер өчен мәшәкатьләрәк соң? Фермерның моңа үз җавабы:

– Барысы да зур игътибар таләп итә. Мин карлыган үстерү алай ук мәшәкатьләдер дип уйламаган идем. Ләкин алай түгел икән. Бакчадагы кебек кенә үстереп булмый монда. Һәркайсын бала караган кебек карарга кирәк. Һәркайсының үз холкы бар. Сезон озакка сузыла. Виктория бетә дә кара карлыган башлана, аннан соң – кура җиләге. Анысы кышка кадәр дәвам итә. Кура җиләгенә алмасы кушыла.

Хәзерге вакытта эшмәкәр 30лап кешене эшле иткән. Сезон вакытында алар 70кә кадәр җитә.

– Бездә бөтен нәрсә кул хезмәте аша уза. Кышын да эшнең тынып торганы юк. Мин моны, бизнес, димим. Беренче чиратта туган ягыма хезмәт итү, халкына эш бирү, дип карыйм. Төзелеш белән чагыштырганда, бакчачылык отышсызрак. Ләкин монда нәтиҗәсен күрәсем килә, дип эшлим. Үземә кызыклы тармак, туган җиргә хезмәт итүдән, кешеләрдән рәхмәт сүзе ишетүдән канәгатьлек алам.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ОНЫТМАСЫН ОНЫК

ШӘһӘР БАЛАСЫ НИ ӨЧЕН ӘБИ-БАБАЙ ЯНЫНА КАЙТМЫЙ?

Мөнәсәбәт

Элек шәһәр баласы җәен авылга кайтырга атлыгып тора иде. Хәзер исә бикле фатирда ятуны кулайрак күрәләр. Интернет тотмау да – бер сәбәп. Авылда кызык түгелме, әллә үзләреннең дә кулыннан телефон төшмәгән әби-бабайның оныклар белән утырырга вакыты калмадымы?

Казанда яшәүче Гөлинә Шиһабиеваның ике баласы бар. Кирәк вакытта аларны Лаеш районына кайтара икән.

– Хәзер инде әби-бабайлар да элеккеге түгел. Кулларында – телефон. Бер генә мәртәбә интернетны актарам, диләр дә дөньяны оныталар. Үзләре дә кайт дип чакырмыйлар. Моңа кадәр бер кәструл ашны бөтенесе бергә утырып ашаса, хәзер ризык талымлыйлар. Берсенә – пылау, икенчесенә пицца кирәк. Прәннек белән кызыктырып булмый. Әбиләр балаларның гел туңдырма, чипсы сорап торганын да яратмый. Акчаны кызганудан түгел бу, ашказаны бозыла дип борчылалар, – ди сөйләде Гөлинә Шиһабиева.

Арча районының Гөберчәк авылындагы Мөхәммәт Мәһдиев музее директоры Халидә Габидуллина әйтүенчә, хәзер шәһәр кешесе ялга сәяхәткә чыгып китә. Балаларын да үзләренә ияртә. Бер сәбәбе шул дип уйлый. Балалар да ишле түгел, бер-ике генә. Элеккеге кебек, әби-бабайга, бәлки, ышаныч та кимегәндер. Хәзер бит сабыйлар – өч ел буе әнисе янында. Казаннан кайтып, авылда әби-бабай янында торучылар сирәк. Арчадан кайтучылар бар.

«Ник кайтмыйлар?» дигән сорауга җавап эзләгәндә, «тормыш үзгәргәнгәдер», «авылда интернет тотмый», «бу кавем безнең кебек түгел», «авылдан шәһәргә тайганнар ничек кайтсын инде...» дигән фикерләрне дә ишеттек.

Кайткан кешенеке кайта ул. Кукмараның Туембаш авылына шалтыраткач, бер гаиләгә – алты, икенчесенә ун бала кунакка кайта, диючеләр дә булды. Чистай районының Йолдыз авылында яшәүче Фаина Шмагинаның биш оныгы бар.

– Дүртесе – Нефтеюганскида, берсе Казанда яши. Әби, сезгә кунакка кайтыйк әле, йә булмаса, үзең килеп ал, дип, җәйне көтеп торалар. Өч ай буе бездә торып китәләр. Рәхәтләнеп урамда уйныйлар. Олыраклары идән сөртә, бакча эшләрендә булыша. Бергәләп каз бәбкәләре саклыйбыз. Кечкенәдән шулай гадәтләндерү кирәк, – ди Фаина Шмагина.

Кукмарада яшәүче блогер, мәдәният өлкәсендә эшләүче Регина Хәкимҗанова башка проблеманы да телгә алды.

– Без өчәр ай буе әти-әнинең туган авылында ял итә идек. Анда дискәтүкләр гөрли, яшьләр бер-берсе белән таныша иде. Бүген клубка чыгарга яшьләр юк. Күбесе өйдә утыра. Әти-әниләр арасында машина алып бирүчеләр дә бар. Кайберләре хәтта кич шәһәргә барып, Казансу буе, Бауман урамнарында йөреп, төнге сәгать 1дә генә әйләнеп кайта. Менә нинди замана! – ди Регина Хәкимҗанова.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Үзе дә 10 яшьлек баласын әбисенә кунакка кайтарган булган. Бала: «Анда интернет тотмый, кызык түгел», – дип озак тормаган. «Авылда интернет начар тота. Шәһәрдә мондый проблема юк. Видео төшереп, «ТикТок»ка, социаль челтәрләргә дә куеп була. Авылга кайтмауда иң зур сәбәпне шул дип уйлыйм», – ди блогер.

Татарстанның халык язучысы Фоат Садриевның да фикерен сораштык.

– Анда элеккечә күңелле түгел. Беренчедән, авыл картайды. Күбрәк өлкәннәр яши. Балаларның кайтырга теләмәве шуңа да бәйледер. Гел картлар белән генә дөнья кызыксыз бит. Урта яшьтәгеләре эшкә чумган. Һәрберсенең җилкәсендә – бурыч. Шәһәрдән кайткан балаларга игътибар да җитмидер. Әби-бабай үзе дә телевизор карый, телефонда утыра, – ди Фоат ага. – Оныкларым кайта. Бераз уйныйлар да диванның ике башына барып утыралар. Ишегалдына куып чыгарып булмый. Бакчада үскән чәчәкләрне борыннарына тидереп тә карыйм. Элегрәк кызыксыналар иде, хәзер юк. Матурлыкны күрмиләр. Кечкенә генә күл ясап, балыклар да җибәрдем. Аңа да игътибар булмады. Мин моны телевизор, телефонга бәйлелектән күрәм. Чөнки ул шулкадәр кызык итеп эшләнгән. Аннан аерыла алмыйлар. Табигатьне яратмаса, аралашуы юк инде андый баланың. Алар йомык булып үсә. Кешенең күңеле ачык булырга тиеш. Бу – иң зур проблема. Без үз-үзебезгә бикләнүгә таба барабыз. Авылның картаюы, таралуы баланың үпкәсенә, җанына, тәненә, канына аның атмосферасы белән бергә керә.

Сәрия МИФТАХОВА

Йөрәк эше

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Рөстәм Миңнеханов Татарстан сәламәтлек саклау тармагының вакытсыз вафат булган элеккеге министры Марат Садыйковны да искә алды.

– Ул сәламәтлек саклау тармагы үсешенә бик зур өлеш кертте. Марат Садыйков ярдәме белән әйдәп баручы клиникага әверелгән 7 номерлы хастаханәгә аның исемен бирергә карар кылдык. Сәламәтлек саклау тармагындагы казанышлары һәм фидакарь хезмәте өчен Россия Президенты Владимир Путин Марат Садыйковны Пирогов ордены белән бүләкләде, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Мәрхүм министрның дәрәҗәле бүләген тормыш иптәше Диләрә Садыйковага тапшырдылар.

Татарстан Рәисе бәйгедә иң көтеп алынган номинация җиңүчесен дә игълан итте. Быел «Ел табибы» дигән дәрәҗәле исемгә Казан дәүләт медицина университетының анестезиология, реаниматология, һәлакәтләр медицинасы бүлеге мөдире Айнагөл Баялиева лаек булды. Ул йөрәк күчереп утырту буенча катлаулы операцияләрдә катнаша. Республиканың берничә клиникасына алдынгы алымнар кертә.

– Командировкаларда еш йөрергә туры килә. Медицина хезмәтләренә бездәге кебек яхшы мөнәсәбәтне башка бер җирдә дә күргәнем юк. Бу мөнәсәбәт безнең эш шартларында да чагыла. Иң матур хастаханәләр бездә. Барысы өчен дә бик зур рәхмәт сезгә, – диде ул, шатлыгы белән уртаклашып.

Яшел Үзән районы акушер-гинекологы Елена Родионова исә Татарстан Рәисенең махсус бүләге – машинага лаек булды. Ул өенә өр-яңа «Лада Гранта» машинасында кайтып китте.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Музыка сәнгатен үстерүгә өлеш кертүе өчен вокалчы артист (солист) **Гашигуллина** Светлана Ивановнага **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең медицина-криминалистика бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты **Акбашев** Виталий Александровичка, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлеге Зеленодольск суд-медицина бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты **Бикмөхәммәтов** Илдар Равил улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор А.Г. Ге исемендәге Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Бильдюк** Евгения Владимировнага, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы гинекология бүлекчәсе мөдире, табибы – акушер-гинекологы **Габитов** Наил Әдһәм улына, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең терапия, гериатрия һәм гаилә медицинасы кафедрасы доценты **Галиева** Зәринә Мөнир кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кардиология бүлекчәсе мөдире – табиб-кардиологы **Гыйльманов** Альберт Әнәс улына, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының клиника-эксперт эше буенча урынбасары **Нестерова** Диларә Фәрид кызына, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының поликлиника бүлеге эше буенча урынбасары **Сәгыйтова** Гүзәл Рим кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы консультация поликлиникасы өлкән шәфкать туташы **Богданова** Светлана Фоат кызына, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш шәфкать туташы **Зиннәтуллина** Надия Ярхәм кызына, «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе табибы-лабораторы, санитария-химия һәм токсик-гигиена тикшеренүләре бүлегенең алкоголь продукциясен тикшерү лабораториясе мөдире **Нәбиуллина** Дилбәр Исмәгыйль кызына, «Кама Тамагы үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең терапия бүлекчәсе өлкән шәфкать туташы **Рыжова** Дамирә Әсхәт кызына, «Апас үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең теш табибы **Сөнгатуллина** Фәния Рөстәм кызына **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Шәхес

Аңлап эш итү кирәк

Быелгы уку елыннан башлап, Россия югары уку йортларында белем алган талантлы студентлар һәм аспирантлар микроэлектроника өлкәсендә фәнни мәктәпкә нигез салучы галим Камил Вәлиев исемендәге стипендия алачак.

Сүз дә юк, әгәр нинди дә булса сәбәпләр белән белмәгән-ишетмәгән булсагыз, беренче чиратта, мөгаен, күбегезне, милләттәшебез буларак, «Кем ул Камил Вәлиев?» дигән сорау кызыксындыра торгандыр. Гаеп түгел, чөнки микроэлектроника ул – бик үзенчәлекле тармак. Мондый өлкәдә бөек ачышлар ясаган, зур эшләр башкарган шәхесләр гадәттә күләгәдә калучан була.

Минем үземә Камил Вәлиев турында Арча педагогия училищесының элеккеге директоры, математика фәненнән укытучым Илдус абый Сәгъдиев сөйләгән иде. Шушы уңайдан бөек галимне тагын бер кат искә төшереп алдык.

– Казан педагогия институтының физмат факультетында укыганда, – диде ул, хатирәләрне барлап, – Камил Әхмәтович иң авыр фәннәрдән – механик һәм теоретик физикадан лекцияләр укыды. Бездән берничә яшькә генә өлкәнрәк булса да, искиткеч укытучы иде ул. Аның лекцияләрен яраттык, калдырмаска тырыштык. Имтиханнар вакытында конспектлар, хәтта дәреслекләр кулланырга рөхсәт итүче бердәнбер кеше булды. Бу җәһәттән: «Иң мөһиме, аңлап эш итү кирәк», – дип әйтергә яратты.

Камил Вәлиев – үзебезнең егет. Ул 1931 елда Мамадыш районының Югары Шүләнгер авылында туа. Бер караганда, тормыш юлы да башкалардан аерылып тормый кебек: мәктәп еллары, Казан дәүләт университетының физика-математика факультеты, аспирантура... Тәгълимати, ягъни теоретик физика белгечлеген үзләштерә. Аннан университетта физика кафедрасының өлкән укытучысы, соңрак мөдире булып эшли. Педагогия институтында да дәресләр алып бара.

Узган гасырның алтмышынчы елларында халыкара мөнәсәбәтләр шактый катлаулана: Кариб кризисы, Кореядагы сугыш, СССР белән Америка космоска оча, шулай ук өченче бөтендөнья сугышы башлану куркынычы туа. Шул җәһәттән илнең иминлеген саклап калу нияте белән Мәскәү янындагы Зеленоград шәһәрендә фәнни-тикшеренү институтлары оештырыла башлый. Шуларның берсе – молекуляр электроника институтына директор итеп 34 (!) яшьлек физика-математика фәннәре докторы Камил Вәлиев билгеләнә. Әле институт кына да түгел. 1967 елда институт каршында «Микрон» исемле интеграль схемалар әзерли торган үз заводы да төзелә башлый. Аның директоры да якташыбыз була. Шул елларда галим космик аппаратлар һәм хәрби системалар белән идарә итү һәм элемтә комплексларын өчен яңа интеграль схемаларның бик күп төрләрен әзерләү һәм җитештерү эшләрен оештыра. Шулар нигезендә ракета системаларына хисаплау машиналары һәм «Эльбрус» исемле компьютер әзерләнә. Марс һәм Венера планеталарына җибәрелгән космик аппаратларда да шул интеграль схемалар кулланыла. 1974 елда ул СССР Фәннәр академиясенең космик тикшеренүләр институтына күчә. Физика институтында микроэлектроника лабораториясе төзи. Соңрак Мәскәү дәүләт университетында һәм физика-техник институтында квантлар информатикасы кафедрасын җитәкли.

Галимне туган җирендә онытмыйлар. Мамадыш шәһәрендәге 2 нче лицей 2016 елдан бирле якташлары, академик Камил Вәлиев исемен йөртә. Музей да эшләп килә. Анда галимнең шәхси әйберләре дә куелган, эшчәнлеге дә яктыртылган.

– Ел саен Россия күләмендә якташыбыз исемендәге конференция үткәрәбез, – ди лицей завучы Илнара Локманова. – Элек Россия төбәкләреннән укучылар үзләре килә иде. Хәзер исә онлайн формада булгач, география бик киңәйде, бик теләп катнашалар.

Кем белә, нәкъ менә шушы яшьләр арасында Камил абыйлары кебек бөек галимнәр килеп чыгар әле.

Фәния САФИНА

Микроэлектроника юнәлешендәге искиткеч зур казанышлары өчен, Камил Әхмәт улы Вәлиев 1974 елда Ленин исемендәге премиягә лаек була. Шулай ук ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Октябрь революциясе ордены, IV һәм III дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» орденнары белән бүләкләнә.

ҮЗ ӨЕМДӘ – ҮЗ КӨЕМ

Сәяхәт

Машинада сәяхәт итү – хәзер күпләр өчен гадәти хәл. Чаллыда яшәүче эшмәкәр Ришат Мортазин да үз машинасын «тәгәрмәчле йорт»ка көйләп, шушы көннәрдә генә Кавказ тауларына хозурланып кайтты. Әйтергә кирәк, бу аның беренче сәяхәте генә түгел. Шулай да, алган тәэсирләр яңарак дип, сүзне соңгысыннан башларга булдык.

:: Ришат, ни өчен Кавказ?

– Бу якларга тартылуның берничә сәбәбе бар. Беренчедән, без тауларны бик тә яратабыз. Икенчедән, Кавказ халкы бик кунакчыл. Алар янында гел буласы, аралашып торасы килә. Моңа кадәр без җиңел машина белән Грузиядә, Азәрбайҗанда булып кайткан идек. 2015 елда Эльбрус түбәсенә дә менеп төштем. Бу юлы бер көнгә уртача 300 км дип исәпләгәндә, барлыгы 6000 км юл үттек. Әллә ни күп түгел ул. Машина йөртүчене эштән чыгара алмый. Төн кунарга урынны да теләсә кайда сайлап була. Мәсәлән, без Элиста үзәгендә дә, Эльбрус тавы итәгендә дә, тау елгалары челтерәвен тыңлап, төрле тыюлыкларда да, Владикавказның җәяүләләр йөри торган урамында да кундык. Үзебезне гел өйдәге кебек хис иттек. Табигатенә килгәндә, әлбәттә инде, Кавказ ул – әйтеп бетермәслек матурлык дөньясы. Кайчакларда, машинадан чыгып, бөтен тирә-якны фотога, камерага төшерәсе яки тын гына калып хозурланасы килә.

:: Сәяхәтнең юнәлешен билгеләдегез, ди. Ничек әзерләнәсез?

– Чыгып киткәндә, безнең өчен әнә шул юнәлешне белү җитә. Гадәттә, сәяхәтне көнләп кенә планлаштырабыз. Нәкъ менә «автойорт» безгә шулай иркенләп йөрергә мөмкинлек бирә дә инде. Төн куну урыны, азык-төлек, душ, туалет эзләп мәшәкатьләнәсе юк чөнки. Аның каравы көтелмәгән яңалыклар, күренешләр белән танышырга вакыт күп кала. Гадәттә берәр «кызыклы нокта» табу эше миңа йөкләнә. Хатыным Гүзәлия хуҗалык эшләре белән шөгыльләнгәндә яки ял иткәндә, интернетны ачам да эзләнәм. Берәр күңелгә ятышлы урын тапсам, ул уртача 100–300 км ераклыкта булырга мөмкин, җыенабыз да чыгып китәбез. Шуңа күрә һәр сәяхәтебез могҗизалар белән туп-тулы.

:: Шулай да чит җирләр бит. Куркыныч түгелме?

– Кайвакыт полиция хезмәткәрләре туктаткалый. Гадәттә, «автойорт»ның төзелеше белән кызыксыналар, безнең дә шулай сәяхәткә чыгасы килә, диләр. Бер таныш булмаган кешеләр өйләренә чәй эчеп чыгарга чакыра. Туристлар белән дә аралашып, туганлашып бетәбез. Сәяхәтнең нәкъ менә шушы төрен иң куркынычсыз дип әйтер идем мин. Иң мөһиме, вакытында бензин салырга, суыткычны азык-төлек белән тутырырга, су запасы булдырырга гына кирәк. Су дигәннән, анысы белән азрак мәшәкать чыккалый. Әмма бу Кавказга кагылмый, монда чишмәләр бик күп. Суы да бик тәмле. Машинабызда 110 литр су сыйдырышлы бак тора. Ул безгә якынча бер атнага җитә. Ә азык-төлеккә килгәндә, күбрәк җирле кухня белән кызыксынабыз. Калмык, балкар, чечен, азәрбайҗан халыкларының милли ашлары бик тәмле. Тәмле булгач, ашыйбыз инде. Шуңа күрә ябыгу, диета тоту турында уйларга мөмкин дә түгел.

:: Сәяхәт иткәндә, «буш вакыт» дигән төшенчә урынлымы?

– Кавказда без өч атна сәяхәт иттек. Көн тәртибен ничек төзисең бит. Аннан килеп, буш вакыт дигән нәрсә үзе дә күп сораулар тудыра инде ул. Шуны гына әйтә алам: эшсезлектән интеккәнебез юк. Безнең «автойорт»та дистанцион эшләр өчен дә шартлар тудырылган. Гүзәлия университетта укыта, аңа күп вакытта онлайн лекцияләр алып барырга туры килә. Бер тапкыр да зарланып карамады. Студентларга кайда йөргәнең, лекцияләрнең нинди шартларда укылганын да күрсәтеп барды. Кызыксынучылар бик күп.

:: Кызыксыну дигәннән, «автойорт» ясау идеясе ничек барлыкка килде?

– Самолетта очып, кунакханәләрдә яшәп, кафеларда ашап, илләр гизгәннән соң, ничектер башкача сәяхәт итеп карыйсы килде. Моңа, бәлки, йортлар салу белән шөгыльләнүем дә ярдәм иткәндер. «Автойорт»ны мин үземчә төзедем: җылыткыч материалларны да үзем сайладым, вентиляцияне дә үзем теләгәнчә үткәрдем. Бик әйбәт килеп чыкты ул. Хәтта ашарга әзерләгәндә салонга ис тә чыкмый.

:: «Йорт»ыгызда ниләр бар?

– Салонда йоклый торган урын бар. Анда ике урынлы карават куелган. Кухня зонасы яктыртылган, газ плитәсе, өстәл, суыткыч бар. Ике душ эшли. Берсе – эчтә, анда салкын булганда юынабыз. Икенчесе тышкы якта. Биотуалет җиһазланган. Хуҗалык әйберләрен урнаштыру өчен тартмалар беркетелгән. Керне раковинада юабыз, бауга элеп киптерәбез.

:: Димәк, «автойорт»та кышкы салкында да сәяхәт итәргә була?

– Мич яхшы җылыта. Тышта минус 25 градус булганда да йоклап караганым булды. Су катмый. Әгәр температура кинәт кенә төшсә, датчиклар эшләп китә һәм бактагы, торбадагы суны җылыту системасы эшли башлый. Түбәдә кояш энергиясен алу өчен зур панель куелган. «Автойорт» тулысынча автоном режимда эшли: Wi-Fi бар, аккумулятор батареялары – кояш энергиясеннән, ә хәрәкәт иткәндә автомобиль генераторыннан «туклана».

:: Мондый «автойорт»ны дәүләт инспекциясендә теркәргә дә кирәктер?

– Әлбәттә. Шунсыз булмый. Беренчедән, теркәлмәгән булса, аны сата алмыйсың. Икенчедән, чит илләрдә, йөк машиналарына кебек үк, зур пошлиналар түләргә туры киләчәк, ә теркәлгән очракта ул җиңел машина исәбендә йөри, бернинди проблема да калмый.



Ришат Мортазинның шәхси архивыннан

:: Бигрәк тә истә калган сәяхәтләр?

– Без 20дән артык илдә булдык. Европа буенча сәяхәт иткәндә, берьюлы 13 илдә йөргән идек. Хәзер инде андый мөмкинлекләр юк. Әмма сәяхәт итәрлек урыннар Россиядә дә, үзебездә дә бик күп. Юл йөргәч, кызык хәлләргә гел юлыгып торасың инде ул. Кайчакларда үзебез дә гажәпләндерәбез. Мәсәлән, Һиндстанда бер авылда тукталган идек. Анда яшәүчеләр гомерләрендә беренче тапкыр чит ил кешеләрен, ягъни безне күрде. Алар өчен гайре табигый хәл булды бу. Табиблар гаиләсенә кунакка чакырдылар. Шундый һөнәрле, зыялы кешеләрнең җир идәнле, ишеге-тәрәзәсе булмаган алачыкта яшәүләрен күреп шаккаттык. Әмма алар зарлануның нәрсә икәнен дә белми. Шундый хәлләрне күргәч, тормыштан гыйбрәт алырга да өйрәнәсең.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Язучы фикере



Марат КӘБИРОВ

Кадерлән үстерәбез...

Шәһәр кешесенә бик сизелми торгандыр инде бу, анда мохит бүтән төрлерәк – табигатьтән чүт кенә читтәрәк яшисе. Ә авылда сизелә. Нык. Хәтта адәм баласының сәерлегенә аптырап китәрлек.

Авылда без әллә нәрсәләр үстерәбез. Бәрәңге, мәсәлән. Уңдырышлырак булсын дип җирне ашлыйбыз, йомшартабыз, әллә нәрсәләр белән эшкәртәбез. Шуннан бәрәңге утыртабыз. Ул шытып чыкканчы ук чүп үләннәр калкына, аларны йолкып ташлыйбыз. Җепселләре дә калмасын дип тырмалап чыгабыз. Бәрәңгенең колагы күренүгә, колорадо коңгызлары җыела. Аларны чүплибез. Шуның ише бөҗәкләр җыелмасын дип агу сиптерәбез. Аннары күмеп чыгабыз. Әле ел коры килсә, су да сиптерәбез. Күмгәч, тагын колорадо корты үҗәтләнә. Тагын агулыйбыз. Ул арада чүп үләннәр баш калкыта. Кәтмәнлибез. Утыйбыз. И, саный китсең, әллә ниләр кыланып бетәбез икән шул бәрәңгене үстерер өчен генә дә.

Чөгендер утыртсак та шул чамарак. Суганы да шул. Кишере дә, кәбестәсе дә, кыяр-помидоры да. Җәй буена шуларны гына тәрбияләп ятсаң да, ял-фәлән күрерлек түгел. Без аларны ихлас күңелдән карыйбыз. Яратып, кадерләп үстерәбез.

Әле аның кош-корты да бар бит. Бер күршебез казларын көн саен елга буена куып төшереп юындырып кайта. Тегеләрнең суда уйнап, күңелләре булганчы саклап утыра. Аннан соң ыштан балакларын бот тиңентен сызганып елгага керә дә корыга куып чыгара. Шулай итмичә булмый, ди. Елга буенда әллә нинди сәер җәнлекләр очрый, казларыңны буып ыргытырга да мөмкиннәр икән.

Бер күршенең егерме биш тавыгын ниндидер җәнлек буып чыккан. Абзарына кереп. Югыйсә авызы ачык, төбе тишек сарай да түгел инде. Тик теге нәрсә барыбер җаен тапкан, җирне казып кергән. Хәзер без, тирә-яктагылар, үзебездә шундый хәл булмасын, дип абзарны ныгытабыз, җирне казып, таштан я цементтан нигез салабыз. Хәтта яңарак кына операция ясатып кайткан Хәниф күрше дә казый. Аңа өч килодан да артыграк нәрсә күтәрергә ярамый, дигәннәр. Врачлар аз гына алдаган бугай. Бу илле килолы цемент капчыкларын да җилтерәтеп йөртә. Чуртым да булмый. Тавыкларның тыныч тормышы безгә акчадан да, сәламәтлектән дә кадерлерәк. Без аларны ярратып үстерәбез.

Безнең урамда яшәүче бер ханым ике тәүлек буена бозавын эзләп йөрде. Авылның һәр квадрат метрын карап чыккан. Күрше авыл көтүенә кушылмады микән дип тирә-як авылларны да урап кайткан. Аяклары сызлый аның, аксаклап йөри. Шул көенчә эзләгән. Мал гына түгел, җан да бит инде ул үзең асраган бозау. Акчаң төшеп калса да, ул кадәр үк кыланмас идең, ә бозау ул – бөтенләй бүтән. Имгәнергә, ерткыч-җанварга эләгергә, сазга батарга мөмкин. Кызганасың бит инде. Шулай булгач, эзләмичә чараң юк. Кадерле ул. Сыер-сарыкларны да без яратып тәрбиялибез. Кадерләп үстерәбез.

Үзең үстергән бөтен нәрсә дә кадерле. Тормышыңа гамь, күңелеңә – ямь, аяк-кулыңа дәрт өстәп торалар. Су сибеп чыксаң, хәтта түтәлләр дә синең белән сөйләшә башлагандай тоела. Рәхмәт әйтәләр, шаярышалар, очкынланып балкып китәләр. Чүп үләннәрне утап чыккач та шулай – түтәлләрдән яктылык сибелә башлый. Ул яктылык әллә кая, Каф тау артына китми бит инде, үзеңнең күңеленә керә, үз көнеңне балкыта.

Шул рәвешле үсемлекләр, җиләк-җимешләр, агачлар, йорт хайваннары белән кеше арасында якты бәйләнеш, җылылык, ягымлылык хасил була. Ярату. Табигать белән кеше арасындагы мәхәббәт. Болай дию, бәлки, мәзәгрәк тоеладыр. Әллә нинди сәер бер халәт инде ул. Иртән торып чыгасың менә – буыннар каткан, сөякләр шыгырдый, әллә кайсы төшләреңә сызлый. Ә синең иркәләнеп торырга чараң юк: тавыкларың нидер өмет итеп кыткылдап йөри, казларың каңгылдаша. Җим әзерләргә, туйдырырга кирәк. Әнә бер түтәленне төн чыкканчы чүп баскан. Утарга кирәк. Шулай хәрәкәтләнеп китәсең дә, тәннәреңә языла, күңелең көрәя, сызланулар җәяүләп кача. Үзеңне үсемлекләргә, кош-кортка, мал-туарга яшәү көче бирүче итеп тоясың. Бер карасаң, чынлап та шулай бит инде, син аларга ризык яки бүтән нәрсәләр аша тормыш бүләк итәсең. Башкаларны яшәтергә теләү үзеңне дә яшәргә мәҗбүр итә.

Менә шул чамарак яши адәм баласы. Ул барысын да үстерә. Бөтен көчен, бөтен ихласлыгын, күңеленең бөтен нурын биреп кадерләп үстерә. Кайчагында үз-үзен дә аяп тормый. Әнә шулай итеп назлап үстерә дә ахыр чиктә тегеләрне ашый. Бәрәңгесен дә, бүтән яшелчәсен дә, җиләк-җимешен дә, кош-кортын да, сыер-сарыгын да – бөтенесен дә. Берсен дә калдырмый. Адәм баласының үзе кадерләп үстергән нәрсәләрнең берсен дә ашамый калдырганы юк. Ашый. Ашамый торганнарын чүплеккә ташлый.

Кызык инде, әйеме...

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Республика агросәнәгате комплексы ветераннар Советы президиумы,

тормыш иптәше

вафат булу сәбәпле, агросәнәгать комплексының мактаулы әгъзасы Солтан Шәрип улы Алиевның, мәрхүмәнең туганнары, балалары, оныкларының авыр кайгысын уртаклаша.

РӘХМӘТЛЕ БӘЙРӘМ

КУКМАРАДА ГЫРОН БЫДТОНДА КҮҢЕЛ АЧТЫЛАР

Язгы кыр эшләре төгәлләнеп, печәнгә төшәр алдыннан, удмурт халкы рәхәтләнеп бер күңел ача. Кукмара районының Нырья авылында удмурт халкының Гырон быдтон бәйрәме гөрләде. Ул республикадан һәм Россия төбәкләреннән 3 меңнән артык кунак һәм илнең 300гә якын иҗади коллектив вәкилләрен җыйды.

Гырон быдтон – удмуртларның табигатькә, Җир-анага рәхмәт әйтү, мул уңыш сорап, дога кылу бәйрәме. Ул язгы чәчү уңышлы тәмамлану уңаеннан, җәйге кояш торышының соңгы көннәрендә, печәнгә төшәр алдыннан уздырыла. Гырон быдтон, гадәттә, берничә көн дәвам итә: яшьләр әйләп-бәйләп, уеннар уйныйлар, шулай ук ярышлар, атта чабу оештырыла. Җиңүчегә бүләк итеп бизәкләп чигелгән сөлге һәм янчыклар бирелә торган булган. Әлеге бүләкләрне кияүдәге хатын-кызлар алдан әзерләгән. Бу көнне туй иткәннәр, яшьләр күмәк күңел ачулар оештырган.

Республикада бу бәйрәмне 1998 елдан зурлап үткәрәләр. Кукмарда узган бәйрәм кунаклары арасында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да бар иде. Төп мәйданга килгәч, рәсми ачылыш алдыннан ул удмурт ишегалдын карады. Биредә кунакларны милли ризыклар белән сыйладылар, гореф-гадәтләр һәм йолалар белән таныштырдылар, удмурт халкының көнкүреше һәм мәдәнияте турында сөйләделәр.

Фәрит Мөхәммәтшин үзенең сәламләү сүзендә кунакчыл Кукмара һәм удмурт халкына мондый милли бәйрәмнәрне республикада бергәләп оештырган өчен рәхмәт белдерде.

– Без мондый очрашуларны һәрвакыт хупладык һәм бер-беребезне милли бәйрәмнәр белән котладык. Гырон быдтон, Сабан туе, Каравон, Семык, Уяв һәм башка бик күп бәйрәмнәр – Татарстанның күпмилләтле халкы арасында дуслыкны һәм татулыкны саклау турында кайгырту һәм көндәлек тормышыбыз. Башкача яшәргә ярамый, – диде парламент җитәкчесе.

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренчә, 173 милләт яшәгән Татарстанда һәркем үзенең гореф-гадәтен, телен, мәдәниятен, киемен, милли ризыгын саклап калырга тели.

– Хезмәт сөючән удмурт халкы әлеге бурычларны хәл итүдә үз өлешен кертә. Без сезнең алда баш иябез һәм сезгә рәхмәт әйтәбез, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Авыл халкы безгә аеруча кадерле, чөнки ул халкыбызның күптөрлелеген, күпмәдәнилеген саклый. Безнең республика күпмилләтле халыкның байлыгын саклый белә, бу байлыкны булдыра белә. Шушы дуслыкны, хөрмәтне без башкаларга да күрсәтергә тырышабыз.

Кукмара районы башлыгы Сергей Димитриев сүзләренә караганда, районда 7000 удмурт кешесе яши. Бу – республикадагы удмуртларның 30 проценты. Удмуртия Дәүләт Советының башлыгы урынбасары Татьяна Ишматова исә Татарстанда яшәүче милләтләргә күрсәткән игътибар өчен республика җитәкчелегенә рәхмәт әйтте. «Бүген Татарстан аша узганда сездәге чисталыкны һәм халыкның ничек бай яшәвен күреп сөендек. Сезнең кебек буласы килә», – диде ул.

Удмурт халкы тырыш кына түгел, биергә һәм җырларга да ярата. Мамадыш районының «Купанча» удмурт ансамбле катнашучысы Татьяна Раимова әнә шулай ди.

tatarstan.ru

– Без мондый зур чараларга еш йөрибез. Барлык традицияләрне, милли бәйрәмнәребезне бергә үткәрәбез. Гырон быдтон – бик кызыклы, күптөрле бәйрәм. Ул – игенчеләрнең, барлык авыл халкының хезмәтен олылау. Удмуртлар – борынгы гореф-гадәтләрен саклап кала алган халык. Туган телебезнең, туган җиребезнең, Ватаныбызның матурлыгын башкаларга да күрсәтергә телибез, – дип сөйләде ул.

Бәйрәмдә төп бизәкләрнең берсе – участка «Вось жук» удмурт боткасы пешерү. Быел 248 кило ризык пешереп, аны «Россия Рекордлар китабы»на кертәчәкләр. Бәйрәмдә уеннар да тынып тормады. Авыш баганада йөрү, мунча себеркесе бәйләү, ераклыкка утын пүләне ыргыту, ат арбасын тартып йөгерү уеннарында халык актив катнашты.

Иске Юмья авылыннан Макаровлар удмурт гаиләсе бәйгесенең җиңүчесе булып танылды. Гырон быдтонда чибәр кыз белән батыр егетне дә сайладылар. Аларда бу ярыш «Чеберина но Батыр» дип атала икән. Төрле районнардан килгән 6 гүзәл зат һәм 4 ир-егет оештыручылар әзерләгән биремнәрне үтәделәр. Халык костюмнары, буыннан-буынга тапшырыла торган традицияләр белән удмурт халкының көнкүрешен күрсәттеләр. Җиңүне Кукмара районыннан Андрей Трофимов һәм Балтач кызы Динә Михайлова яулады. Киләсе бәйрәм Менделеевск районында үткәреләчәк.

Ләйсән САФИНА

КАРТЛЫККА КУЛ СЕЛТӘП...

ТАТАР ТОМБАРЛЫСЫНДА ӘБИ-БАБАЙЛАР УТ УЙНАТТЫ

Баулы районының Татар Томбарлысы авылы әби-бабайлары, таякларын ташлап, янә мәйданга чыкты. Монда 58 нче мәртәбә Әбиләр Сабан туе үтте. Ел саен яңа уеннар өстәлсә дә, бәйрәмнең рухы, борынгы гадәтләр югалмый. Иң мөһиме – өлкәннәрнең күңеле – унсигездә! Томбарлылар мактана ала: мондый бәйрәм әлегә республиканың бер генә районында да юк.

Быел республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы икәнлеген истә тотып, чараны оештыручылар фотога төшерү урыны да булдырган. Музейдан сандык, бишек, кое һәм башка борынгы җиһазлар, чиккән мендәрләр, тәрәзә пәрдәләре алып килеп, татар өе ясаганнар. Телисең икән, йон эрләп фотога төш. «Кое»дан су алып кара.

Әбиләр Сабан туе күңеллерәк була икән. Ни өчен дигәндә, халкы да, катнашырга теләүчесе дә күбрәк. Сабан туена Баулыдан гына түгел, Мәскәү, Казан шәһәрләреннән, Себердән авылдашлар да кайта. Әнә Себердән кайткан Галимҗановлар бишәүләп гармунда уйнап, мәйдан халкын шаккатырган. Өлкәннәрнең «Хәтирә» фольклор ансамбле дә бәйрәмгә бизәк өстәгән. Бии дә, җырлый да үзләре. Сабан туе гади дә, шул ук вакытта ихлас үтүе белән дә аерылып тора. Аның үз энергетикасы бар.

Китапханәче Эльвира Әхмәтҗанова әйтүенчә, быел чаңгы ярышы да үткәргәннәр. Өлкәннәр тун-бүрекләр киеп, яшел чирәмдә осталыкта сынашкан. Өлкәннәр катыктан акча эзләгән, көянтә-чиләк белән су ташыган, капчык киеп тә сикергән, балык та тоткан, чүкеч белән кадак та каккан. Сулы табакта да биегән. Кемнең суы беренче бетә, шуңа бүләккә – табак. Кыскасы, бу көнне бабайлар – егеткә, әбиләр кызга әйләнә. Күңелләре җилкенеп тора.

91 яшьлек Гамир бабай Юзаев агач чүкеч белән кадак кагу ярышында җиңеп, пычак кайрагыч откан. «100ле» кадакны бер сугуда керткән ул. Бабай колакка катырак. Шуңа күрә килене Эльмира белән сөйләштек. Бабай биергә бик оста икән. Уеннарда катнашып, бүләкләр откан.

– Йокыдан иң беренче булып торып, матур киемнәрен киеп, бәйрәмгә барырга атлыгып тора ул. Уеннарда катнашырга ярата. Без гаиләбез белән бергәләп бардык. Мин үзем тамашаны карап кына утырам, – ди 56 яшьлек Эльмира ханым.

Моңа кадәр авыл агайлары ат җигеп, аны туарып күрсәтсә, быел әлеге уенны үткәрмәгәннәр.

– Башка елларны ат җигү ярышында беренче урынны ала идем. Мин бит бригадир ярдәмчесе булып эшләдем. Шуңа күрә минем өчен бернинди авырлыгы да юк моның. Әти белән атта утынга бара идек. Кечкенәдән җигә дә, тугара да беләм. Шуңа күрә бу уен бик якын миңа, – ди 56 яшьлек Рәйсә апа Миңнегулова. – Хәзер авылда атлар сирәк. Хуҗалыктагы эшне трактор белән башкаралар. Ярышка алып чыгу өчен атның тыңлый торганы кирәк бит.

Рәйсә апа башка елларда «агач ат»та да чапкан, чүлмәк тә ваткан, көянтә-чиләк күтәреп тә йөгергән. Быел аягы сынаткач, уеннарда катнаша алмаган. Шулай да Зөһрә Шәрифуллина башкаруындагы бер җырны җырлап кайткан әле. «Әбиләр Сабан туен бик яратабыз. Халыкны бер гаилә кебек туплый ул. Мохите дә үзгә бер җылы аның. Бүләкләре дә әйбәт», – ди Рәйсә апа.

Авылның иң өлкән әбисен билгеләп, бүләк бирү гадәте дә бар. Ул – элек татар теле укыткан 99 яшьлек Фәхриҗамал әби Шәрапова (июль аенда 100 яшь тула). Тик Фәхриҗамал әбигә ашка китәргә туры килгән шул. Бүләген исә өенә барып тапшырачаклар.

Бәйрәмне алып баручы мәдәният йорты директоры Айгөл Нәүрүзбаева хыялы белән дә уртаклашты:

– Иганәчеләр ярдәме белән Әбиләр Сабан туе узган урынны матур итеп ясап, өлкәннәргә милли киемнәр тектереп, тагын да ямьләндерәсе килә. Республика күләменә күтәрәсе иде аны. Башка авыллардагы әби-бабайлар да безгә килеп, уеннарда катнашып, күңел ачып китәр иде. Картлар йортындагы әби-бабайларны да чакырырга мөмкин. Әбиләр Сабан туе өлкән буынга хөрмәтне күрсәтә, киләчәктә дә бәйрәмнең асылын югалтмаска иде. Без халкыбызның борынгы гадәтләрен яшь буынга күрсәтәбез. Алар моны күреп, аңлап үсә.

Сәрия МИФТАХОВА

Чулман буенда

Чаллы

«Москвич»та кайтып киткән баш батыр, ат чабышында җиңгән Полина. Чаллы Сабан туеның төп геройлары әнә шулар булгандыр, мөгаен. 17 июньдә узган бәйрәмгә җәмгысы 100 меңләп кеше килгән, ди рәсми чыганаклар.

Күңел ачу – бер нәрсә, Сабан туе мәйданы – беренче чиратта, берләштерә торган урын ул. Сабан туе үзе дә – киләчәккә өмет һәм ышанычны арттыра торган бәйрәм. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның котлавында әнә шундый юллар бар иде. Республика җитәкчелеге исеменнән Чаллы халкын һәм кунакларын Премьер-министр Алексей Песошин тәбрикләде.

Автокала мэры Наил Мәһдиев исә Сабан туе мәйданын төрле милләт вәкилләренең очрашу урыны дип атады. «Бүген монда Чаллыда дус-тату яшәүче 80 милләт вәкиле бәйрәм итә», – диде ул.

Сүз уңаеннан, Чаллы мэры Кубогына уздырылган ат чабышында, бар кешене таң калдырып, Менделеевск районыннан Полина Кузнецова җиңде. Ә көрәштә баш батыр исемен Чаллы егете Эльдар Хәмитов яулады һәм өр-яңа «Москвич»лы булды.

Түбән Кама

Морозовлар көрәше, 100 килолы тәкә һәм атлар өстендә «Аударыш». 18 июньдә Түбән Кама халкы һәм кунаклары – барысы бергә 30 меңләп кеше кыр бәйрәмен гөрләтте.

Аларны үз исеменнән һәм республика җитәкчелеге исеменнән котларга килгән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтмешли, әлеге бәйрәм, иң беренче чиратта, кыр батырларын данларга тиеш. «Бу мәйданның төп кунаклары – авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре. Без сезнең алда баш иябез!» – диде ул.

Түбән Кама районы башлыгы Рамил Муллин Сабан туеның татар халкы өчен генә түгел, башка халыклар өчен дә яраткан бәйрәменә әйләнүен искәртте.

Бәйрәмнең иң күңелле мизгелләре көрәш мәйданында булды, дисәк, ялгышмабыз. Хәлиткеч бил алышуда көрәшкән бертуган Константин һәм Артем Морозовлар Түбән Кама Сабан туеның тарихына кереп калыр, мөгаен. Ахыр чиктә 100 килолы тәкә һәм 100 мең сумлык акчалата бүләк иясе булып Константин Морозов танылды. Шулай ук бәйрәмдә тәүге тапкыр төрки халыкларының «Аударыш» уены, ягъни ат өстендә көрәш узды.

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5315 данә
Гомуми тираж – 14253 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 286

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә күл куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+